КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2025 ел, 1 февраль г.Казань № 51

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге) турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2021 ел, 23 сентябрь, 909 нчы карары белән расланган Татарстан Республикасында социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге) турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге) турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2021 ел, 23 сентябрь, 909 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 ел, 27 декабрь, 1298 нче; 2022 ел, 26 гыйнвар, 47 нче; 2023 ел, 2 май, 556 нчы; 2024 ел, 10 декабрь, 1131 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасында социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге) турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.8 пункт үз көчен югалткан дип танырга;

2.7 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.7. Министрлык төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге) объектлары һәм аларга бәйле контрольдә тотыла торган затлар исемлеген (алга таба – Контрольдә тотыла торган объектлар исемлеге) алып бара. Контрольдә тотыла торган объектлар исемлегендә түбәндәге мәгълүмат бирелә:

юридик затның тулы исеме, индивидуаль эшмәкәрнең фамилиясе, исеме һәм атасының исеме (булганда);

төп дәүләт теркәү номеры;

салым түләүченең индивидуаль номеры;

контрольдә тотыла торган затның урнашу (эшчәнлек башкару) урыны;

зыян (зарар) китерү рискы категориясе турында белешмәләр (алга таба – риск категориясе).»;

2.8 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.8. Контрольдә тотыла торган объектлар исемлеген алып бару тәртибе Министрлык тарафыннан билгеләнә.»;

2.9 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.9. Министрлык тарафыннан Федераль дәүләт контроле, төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге), муниципаль контроль төрләренең бердәм реестрында (алга таба – Бердәм реестр) Контрольдә тотыла торган объектлар исемлеге алып барыла һәм һәм Бердәм реестрның рәсми сайтындагы бер өлеше Министрлыкның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында тиешле Контрольдә тотыла торган объектлар исемлеген (виджетны) күрсәтү өчен «Интернет» челтәрендә бастырып чыгарыла.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин